
Чыгу көне: 30.11.2021






**Бу чыгарылышта:**


| | |
|---|---|
| Ана— шәфкать диңгезе | 1 |
| Мәктәп яңалыклары | 2-4 |


Әниләр көне билгеләп үтелмәгән бер генә ил дә юктыр, мөгаен. Россиядә Әниләр көнен күптән түгел генә билгеләп үтә башладылар. Россия Федерациясе Президенты .Н.Ельцинның 1998 елның 30 гыйнварында имзаланган указы буенча ул ноябрьнең соңгы якшәмбесендә бәйрәм ителә. Дәүләт Думасының хатын-кызлар, гаилә һәм яшьләр эшләре буенча комитеты Әниләр көнен гамәлгә кую инициативасы белән чыкты.

Соңгы вакытта бу көнгә багышланган мәдәни-массакүләм чаралар күбрәк үткәрелә һәм алар безнең илнең бөтен төбәкләрендә уза, аларның күбесе җирле хакимиятләр оештыруында һәм ярдәмендә үткәрелә. Россия Федерациясенең 60тан артык субъектында балаларны тәрбияләү һәм төбәк гаилә сәясәтен чынга ашыруга өлеш керткәне өчен әниләргә дипломнар, медальләр, мактау билгеләре, исемнәр һәм премияләр гамәлгә куелган. Алар бу бәйрәм уңаеннан уздырылган чараларда тапшырыла.

Искәртеп үтик, Европа илләренең күбесендә, АКШ, Канада, Кытай, Япониядә Әниләр көне май аеның икенче якшәмбесендә билгеләп үтелә.

**Котлыйбыз!**

18-21 нче ноябрь көннәрендә мәктәбе-

**Игътибар итегез!**

Кадерле укучылар!

Ноябрь – декабрь айлары- олимпиада узу вакытлары. Барыгызга да уңышлар телибез!

без директоры белән директор урынбасарлары Санкт -Петербург шәһәрендә узган "Образовательная организация XXI века. Лига лидеров - 2021" бөтенроссия бәйгесендә катнашып, 2 номинациядә лауреат булдылар.

Без аларны чын күңелдән котлыйбыз!

**Без булдырабыз!**

19 нчы ноябрь көнне безнең укучыларыбыз

Б. Матакта “Проба пера” дигән Республика бадминтон ярышында катнашып, югары үрләр яуладылар.

Безнең мәктәбебездән 2007- 2008 нче елгы 2 команда катнашты. Алар Бөтенроссия турнирына керергә тырыштылар һәм теләкләренә ирештеләр.

Афәрин!

**Без хәйриядә катнашабыз.**

Мәктәбебез “Умиление” үзәгенә ярдәм күрсәтте.

Укучыларыбыз мәктәп, кәнкүреш кирәк - яраклары, йомшак уенчыклар алып килделәр.

Бу акциядә катнашучыларның барысына да олы рәхмәбезне белдерәбез!









# «Татар кызы-2022»





Быелгы бәйге 1 октябрьдән үк башланды. Укучылар башта үз мәктәпләрендә сынау уза, соңыннан ярышлар район эчендә үтә. Иң яхшы дип табылган «алтын бөртекләр» генә Казанның җиде районы исеменнән финалга чыга.Безнең мәктәбебезнең 9нчы В сыйныф укучысы Фәтхиева Алинә район турында җиңеп, шәһәр турына чыкты. Бәйгенең беренче өлешендә егет-кызлар үзләре белән таныштырды. Яшьләр сәхнәдә, милли киемнәрдән чыгып, татар кызы белән татар егетенең асылы турында сөйләде.

Бәйгенең икенче өлешендә укучылар танылган татар язучылары, шагыйрьләре әсәрләреннән өзек сәхнәләштерделәр.

Фәтхиева Алинәне «Татар кызы. Татар егете-2021» шәһәр бәйгесендә «Иң ихлас кыз» номинациясендә җиңүе белән котлыйбыз!

Алга таба да уңышлар һәм иҗади җиңүләр телибез!





# Эшлекле әңгәмә





Безнең мәктәбебез, проект кысаларында уза торган «Алдынгылар белән әңгәмә” дигән эшлекле иртәнге ашларны, бик еш үткәрә. 25 нче ноябрь кунагы Аюпов Равил Җәүдал улы иде.

Ул ——теш табибы, «Райдента» стоматолог үзәге җитәкчесе. Равил Җәүдал улы укучыларның сорауларына җавап биреп, эш тәртибе, этаплары белән таныштырды.

Аның укучыларга киңәше : «Тормышта белем бик кирәк, һәрвакыт белем туплагыз, укыгыз»!

Редакциянең адресы:
420101, Казан шәһәре,
Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576
Тираж – 50 экз.

Баш мөхәррир һәм дизайнер: Габдуллаҗанова А.Ф.

Редколлегия әгъзалары: Сафина Камилла, Соколова София, Овезова Ләйлә, Курняева Юлия